ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 28 июне** **Чистай шәһәре** **№ 356**

«2015-2023 елларга Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районында коррупциягә
каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль
программасына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында

Коррупциягә каршы көрәш системасын камилләштерү, Чистай муниципаль районында коррупцион хокук бозуларны кисәтүгә ярдәм итүче чараларның нәтиҗәлелеген арттыру һәм «2015-2023 елларга Татарстан Республикасы коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 21 июнендәге 485 номерлы карарын үтәү максатларында Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2015-2023 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы» 2014 елның 20 ноябрендәге 736 номерлы (Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 16 маендагы 317 номерлы, 2018 елның 27 августындагы 699 номерлы, 2019 елның 1 февралендәге 46 номерлы, 2019 елның 4 сентябрендәге 453 номерлы, 2020 елның 22 июнендәге 328 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә, 1 пунктта «2015-2023» саннарын «2015-2024» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге карар белән расланган «2015-2023 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасында (алга таба – Программа):

исемендә «2015-2023» саннарын «2015-2024» саннарына алмаштырырга;

Программа паспортында:

«Программа исеме» юлында «2015-2023» саннарын заменить «2015-2024» саннарына алмаштырырга;

«Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары» юлында «2015-2023» саннарын «2015-2024» саннарына алмаштырырга;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2015-2024 елларда районның җирле бюджеты акчалары хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 458 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: (сум)

| Ел | ТР Чистай муниципаль районының җирле бюджеты акчалары |
|---|---|
| 2015 | 42,0 |
| 2016 | 42,0 |
| 2017 | 42,0 |
| 2018 | 42,0 |
| 2019 | 48,0 |
| 2020 | 48,0 |
| 2021 | 48,0 |
| 2022 | 48,0 |
| 2023 | 48,0 |
| 2024 | 50,0 |

Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм Чистай муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш.

Моннан тыш, Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелгән акчалардан файдалану күздә тотыла»;

Программаның IV бүлегенең бишенче абзацында, «2023 елга» сүзләрен «2024 елга» сүзләренә алмаштырырга;

Программаның кушымтасында «2015-2023» саннарын «2015-2024» саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен үз өстемә алам.

Башкарма комитет
җитәкчесе                                                            Э.Р. Хәсәнов